ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» февраль 2021 ел. № 45

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
җирләрен рекультивацияләү мәсьәләләре буенча
даими комиссия төзү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 15 11 декабрендәге 689 номерлы карары, Россия Табигый ресурслар министрлыгы һәм Дәүләт җир комитетының "Җирләрне рекультивацияләү, туфракның уңдырышлы катламын алу, саклау һәм рациональ файдалану турындагы нигезләмәне раслау турында" 1995 елның 22 декабрендәге 525/67 номерлы боерыгының 14 п., Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 24 маендагы 813-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге составта Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирләрен рекультивацияләү мәсьәләләре буенча даими комиссия төзергә:

Нурисламов Ришат Тимер улы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы комиссиясе рәисе, район башлыгы урынбасары (килештерү буенча);

Гатауллин Дилүс Гаскәр улы - комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча);

Харисова Татьяна Аркадьевна - комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге баш белгече;

Комиссия әгъзалары:

Баженова Ольга Алексеевна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Поносов Эдуард Александрович - Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Васильев Игорь Григорьевич - "Агрофирма-Әгерҗе" ААҖ директоры (килештерү буенча);

Шәмсиев Рәшид Зәки улы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында "Җир бюросы" ҖЧҖ директоры (килештерү буенча).

2.«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирләрен рекультивацияләү мәсьәләләре буенча даими комиссия төзү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 10 июлендәге 276 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**